КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 июнь г.Казань № 491

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче; 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август, 595 нче; 2018 ел, 22 август, 684 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1280 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1204 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта:

уналтынчы абзацта «Татарстан Республикасы Ммәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

егерме җиденче – егерме сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлек;

билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан билгеләнә.»;

3.3 пунктның егерме алтынчы абзацында «коммерциячел булмаган оешма» сүзләреннән соң «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган,» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карарның җиденче абзацы 2020 елның 15 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин